КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 20 февраль г.Казань № 92

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче кайбер категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 7 июль, 251 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 5 сентябрь, 432 нче; 2007 ел, 5 февраль, 35 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2010 ел, 29 ноябрь, 961 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 13 февраль, 83 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче, 2019 ел, 13 март, 181 нче, 2020 ел, 23 ноябрь, 1053 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнарның авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче кайбер категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибенә, $11^1$ пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«$11^1$. Субсидия-ташламалар бирү мөрәҗәгать итүченең торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычы булган очракта, барлыкка килгән бурычны каплаганга кадәр яки алучы тарафыннан аны каплау буенча килешү төзелгәнгә һәм (яисә) башкарылганчыга кадәр туктатыла.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 ел, 24 март, 126 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 3 июнь, 370 нче; 2009 ел, 6 апрель, 203 нче; 2012 ел, 23 февраль, 153 нче; 2013

ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 25 август, 611 нче; 2015 ел, 23 сентябрь, 701 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 998 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 11 март, 168 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче, 2019 ел, 20 декабрь, 1173 нче, 2020 ел, 02 июнь, 461 нче, 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә, 2.4 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Субсидия-ташламалар бирү мөрәҗәгать итүченең торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычы булган очракта, барлыкка килгән бурычны каплаганга кадәр яки алучы тарафыннан аны каплау буенча килешү төзелгәнгә һәм (яисә) башкарылганчыга кадәр туктатыла.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү өчен кертем түләү чыгымнарын компенсацияләү турында» 2018 ел, 22 август, 680 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 10 декабрь, 1105 нче, 2019 ел, 13 март, 181 нче, 2020 ел, 02 июнь, 461 нче, 2020 е, 16 декабрь, 1141 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү өчен кертем түләү чыгымнарын компенсацияләү тәртибе турындагы нигезләмә, 2.8 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Компенсация бирү мөрәҗәгать итүченең торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычы булган очракта, барлыкка килгән бурычны каплаганга кадәр яки алучы тарафыннан аны каплау буенча килешү төзелгәнгә һәм (яисә) башкарылганчыга кадәр туктатыла.».

4. Бу карарның гамәле 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин